**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 25 » 06 2018 ел** **№ 128**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 17 апрелендәге 74 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламенты турында» Азнакай муниципаль районы чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәреш кертү турында (2014 елның 11 августындагы 152 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 233 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге 214 номерлы, 2017 елның 10 маендагы 120 номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге 77 номерлы карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 07 маендагы 01-51/2649 номерлы "ТКМВ турында" хатын исәпкә алып карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 17 апрелендәге 74 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламенты турында» Азнакай муниципаль районы чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентына (2014 елның 11 августындагы 152 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 233 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге 214 номерлы, 2017 елның 10 маендагы 120 номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге 77 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлектәге 1.9,1.10 пунктлар белән тулыландырырга:

«1.9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында хакимиятнең башка органнарыннан соратып алына торган документлар исемлеге:

- юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

- күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән алыш-биреш килешүләреннән өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган).

1.10. Контроль-күзәтчелек чараларын үткәргәндә юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге:

- вазыйфаи зат паспортының күчермәсе;
- вазыйфаи затларны билгеләү турында боерыклар. »;

1.2. 1.9 - 1.11 пунктын 1.11 - 1.13 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет-телекоммуникация челтәренең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов